| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2019 Зур Тигәнәле авылы № 129

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында " 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында»,

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге советы карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең 2015 елның 26 январендәге 89а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- 8 нче статьяның 3 нче пункт 6 нчы абзацында "бюджет акчаларының баш администраторлары” сүзләрен “бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары” (алга таба - бюджет акчаларының баш администраторлары) - сүзләренә алыштырырга, “эчке финанс тикшерүе һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;
- 13 нче статьяның 3,4 нче абзацында «алынган» сүзләрен "җәлеп ителгән" сүзенә алмаштырырга»;
- 13 нче статьяның 5,12 нче абзацлары, үз көчләрен югалткан дип танырга;
- 13 нче статьяның 17-19 нчы абзацларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Агымдагы финанс елы башына җирле бюджет акчаларының калдыклары: муниципаль юл фондының хисап финанс елында файдаланылмаган бюджет

ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының хокукый акты белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында, вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга, һәм муниципаль берәмлек исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә ,муниципаль контрактлар төзүгә, муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә алалар, финанс хисап елында бирелүе күрсәтелгән субсидияләр алучыларның финанс тәэминаты чыганагы булган акчалата йөкләмәләрен әлеге максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә финанс хисап елында юридик затларга субсидияләр бирүгә, бюджет ассигнованиеләре күрсәтелгән максатларга финанс хисап елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә түләнергә тиеш";

муниципаль берәмлек бурыч алуларының әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгының уртача яисә түбән дәрәҗәсе булган заемчылар төркеменә кертелгән гомуми суммасыннан артып китү күләмендә, җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән чараларның гомуми суммасыннан, һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып китмәгән, агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен киметүче түләүләрне гамәлгә ашыруга җибәрелә.»;

-13 нче статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Җирле бюджет кытлыгын тышкы финанслау чыганаклары составына кертелә:

максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән һәм муниципаль берәмлек тарафыннан түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

муниципаль гарантияләрне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән чит ил валютасында муниципаль берәмлек гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме.»;

-32 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Авыл җирлеге башкарма комитеты, агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, бәяләмә әзерләү өчен, җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап тапшыра. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бер үк вакытта аңа бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализ ясалган аңлатма язуы, дәүләт (муниципаль) биременең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр, карар проекты һәм җирлек Советына җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта тапшырылырга тиешле башка документлар тапшырыла. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү эшләре бер айдан да артмаган вакытта башкарыла. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка нәтиҗә бер үк вакытта җирлек Советына,

Җирлекнең башкарма комитетына район Контроль-хисап палатасы тарафыннан тапшырыла.»;

-32 нче статьяның 3 нче пункты 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бер үк вакытта аңа бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализ ясалган аңлатма язуы, дәүләт (муниципаль) заданиесенең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр, җирлек Советының бюджеты үтәлеше турында карар проекты, җирлек бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла.»;

- 33 нче статья 1 нче бүлектән «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**